ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1699**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Спорт көрәш мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм Зеленодольск муниципаль районының 2022 елның 24 июнендәге муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (бәяләрне) билгеләү өлешендә тарифларны (бәяләрне) карап тикшерү комиссиясе карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Спорт көрәш мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 апрелендәге 819 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 124 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябрендә үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Совет аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетның
2022 елның 08 июлендәге
1699 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**"Спорт көрәш мәктәбе"**
**муниципаль бюджет учреждениесе**

**Түләүле хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм хезмәтләр исемлеге**

| Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, (сум.) |
|---|---|---|
| Спорт төрләре буенча тренировка процессын оештыру һәм уздыру: | | |
| спорт (грек-рим) көрәше | 1 дәрес | 200 |
| дзюдо | 1 дәрес | 200 |
| самбо | 1 дәрес | 200 |
| көрәш | 1 дәрес | 200 |
| Уку-күнегүләр үткәрү өчен физкультура-савыктыру һәм спорт корылмалары (объектлар) бирү, физкультура-савыктыру ярышлары: | | |
| спорт залы (273,4 кв.м) | сәгатенә | 1200 |
| ½ спорт залы (273,4 кв.м) | сәгатенә | 600 |
| спорт залы (130,5 кв.м) | сәгатенә | 800 |